КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 декабрь г.Казань № 1621

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы социаль яклау дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 10 апрель, 237 нче; 2021 ел, 20 июль, 605 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 21 октябрь, 990 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 10 июнь, 543 нче; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче; 2023 ел, 3 июль, 779 нчы; 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренәхезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

6.2 пунктта:

6.2.2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекләренең сәламәтлек саклау һәм икенче һәм өченче дәрәҗәләрдәге социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, «комплекслы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог)», «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» вазыйфасын башкаручы хезмәткәрләренә вазыйфаи окладтан 110 процент күләмендә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр билгеләнә.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекләренең сәламәтлек саклау һәм дүртенче дәрәҗәдәге социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазыйфаи окладтан 120 процент күләмендә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр билгеләнә.»;

6.2.7 пунктчаның икенче абзацында «тәртибе, шартлары» сүзләрен «шартлары» сүзенә алмаштырырга;

6.3 пунктта:

6.3.2 пунктчада:

сигезенче абзацта «2 нче кушымтада» сүзләрен «1 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекләренең мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазыйфаи окладтан 110 процент күләмендә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр билгеләнә.»;

6 нчы таблицаның 1 пунктындагы 3 графасында «өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр,» сүзләреннән соң «кече тәрбиячеләр,» сүзләрен өстәргә;

6.3.7 пунктчаның икенче абзацында «тәртибе, шартлары» сүзләрен «шартлары» сүзенә алмаштырырга;

6.5 пунктның 6.5.8 пунктчасындагы икенче абзацында «тәртибе, шартлары» сүзләрен «шартлары» сүзенә алмаштырырга;

6.6 пунктның 6.6.2 пунктчасындагы сигезенче абзацында «2 нче кушымтада» сүзләрен «1 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекләренең социаль-психологик, социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы җитәкчеләр,

белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә вазыйфаи окладтан 135 процент күләмендә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр билгеләнә.»;

1 таблицада:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инженер, хезмәтне саклау буенча кече белгеч, хезмәтне саклау буенча белгеч, хезмәтне саклау буенча баш (төп) белгеч, хезмәтне саклау хезмәте җитәкчесе, хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне саклау идарәсе башлыгы, хезмәт шартлары һәм аны саклау буенча эксперт, хезмәт шартлары һәм аларны саклау һәм һөнәри рисклар белән идарә итү буенча консультант, хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау инструкторы, һөнәри рисклар белән идарә итү оешмасы җитәкчесе урынбасары, оешмада һөнәри рисклар белән идарә итү юнәлеше (бүлекчәсе) җитәкчесе | хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм хезмәт өчен түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү буенча лаборатория (бюро) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, инженер, хезмәтне саклау буенча кече белгеч, хезмәтне саклау буенча белгеч, хезмәтне саклау буенча баш (төп) белгеч, хезмәтне саклау хезмәте җитәкчесе, хезмәтне саклау идарәсе башлыгы, хезмәт шартлары һәм аны саклау буенча эксперт, хезмәт шартлары һәм аларны саклау һәм һөнәри рисклар белән идарә итү буенча консультант, хезмәт шартлары һәм аны саклау инструкторы, һөнәри рисклар белән идарә итү оешмасы җитәкчесе урынбасары, оешмада һөнәри рисклар белән идарә итү юнәлеше (бүлекчәсе) җитәкчесе»; |

түбәндәге эчтәлекле 52 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «52. | Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча инженер, гражданнар оборонасы белгече, гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча белгеч, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча белгеч, гражданнарны яклау буенча белгеч, гражданнар оборонасы буенча төп белгеч, гадәттән тыш хәлләрдә саклау | гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча инженер, гражданнар оборонасы белгече, гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча белгеч, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча белгеч, гражданнарны яклау буенча белгеч, гражданнар |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча төп белгеч; гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча төп белгеч, гражданнарны яклау буенча төп белгеч, гражданнар оборонасы буенча баш белгеч, гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча баш белгеч, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча баш белгеч, гражданнарны яклау буенча баш белгеч, гражданнар оборонасы бүлеге башлыгы, гадәттән тыш хәлләрдә саклау хезмәте башлыгы, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау идарәсе башлыгы, гражданнарны саклау идарәсе җитәкчесе, гражданнар оборонасы оешмасы җитәкчесе урынбасары, гадәттән тыш хәлләрдә саклау оешмасы җитәкчесе урынбасары, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау оешмасы җитәкчесе урынбасары, гражданнарны саклау оешмасы җитәкчесе урынбасары | оборонасы буенча төп белгеч, гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча төп белгеч; гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча төп белгеч, гражданнарны яклау буенча төп белгеч, гражданнар оборонасы буенча баш белгеч, гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча баш белгеч, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау буенча баш белгеч, гражданнарны яклау буенча баш белгеч, гражданнар оборонасы бүлеге башлыгы, гадәттән тыш хәлләрдә саклау хезмәте башлыгы, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау идарәсе башлыгы, гражданнарны саклау идарәсе җитәкчесе, гражданнар оборонасы оешмасы җитәкчесе урынбасары, гадәттән тыш хәлләрдә саклау оешмасы җитәкчесе урынбасары, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау оешмасы җитәкчесе урынбасары, гражданнарны саклау оешмасы җитәкчесе урынбасары». |

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин